**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Югары Чура авыл җирлеге башлыгы**
**карары**

**2023 елның 14 ноябре** **№ 8**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1 2023 елның 29 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Пчеловод авылы, Үзәк урам, 24 адресы буенча урнашкан Пчеловод авылы клубы бинасында үткәрергә.

2 2023 елның 29 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Пчеловод авылы, Үзәк урам, 24 адресы буенча урнашкан Пчеловод авылы клубы бинасында үткәрергә.

3 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Пчеловод авылына урам яктырту лампалары сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;

- Пчеловод авылының урамнарына вак таш җәю һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- насослар сатып алу һәм артезиан скважиналарын, су башняларын, су саклау зоналарын карап тоту, Пчеловод авылын су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү;

- Пчеловод авылында чишмә янында ял итү зоналары, балалар һәм спорт уен мәйданчыклары территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылында зиратны карап тоту;

- Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машинист-тракторчы хезмәте;

- Пчеловод авылында су башнялары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;

- Пчеловод авылына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру һәм видеокүзәтү системаларын урнаштыру; видеокамераларны һәм видеокүзәтү системаларын ремонтлау һәм карап тоту;

- Пчеловод авылы Урман урамы юлларына асфальт салу һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылында балалар һәм спорт мәйданчыкларын һәм якын-тирә территорияләрне яктырту; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылында чишмәне төзекләндерү һәм карап тоту?

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы: В.Н. Андреев